ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 464-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 464-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2176-VI ДС

Икенче укылышка
әзерләнгән
464-6 номерлы проект

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) югары технологияләр өлкәсендәге технопарк – сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновация эшчәнлеген, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерциячел яисә коммерциячел булмаган коммуналь оешма тарафыннан идарә ителә торган технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларының, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның җыелмасы;»;

б) 2 өлештә «Федераль законда» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «әлеге Законда» сүзләрен «Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8) югары технологияләр өлкәсендәге технопарк – сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновация эшчәнлеген, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерциячел яисә коммерциячел булмаган коммуналь оешма тарафыннан идарә ителә торган технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларының, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның җыелмасы;»;

2) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктта «идарәче компанияләренә» сүзләреннән соң «югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә,» сүзләрен өстәргә;

б) 7 пунктта «технопаркларына» сүзеннән соң «, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга»;

в) 11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 12 статьяның 4 өлешендә «вәкаләтле органы» сүзләреннән соң «(алга таба – икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган)» сүзләрен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле $12^2$ статья өстәргә:

«$12^2$ статья. **Югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар**

1. Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенә һәм сәнәгать продукциясен җитештерүне тәэмин итү һәм (яисә) базарга яңа продуктлар, технологияләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр чыгару максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновация эшчәнлеген, һәм (яисә) мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның составында булган технологик инфраструктура, транспорт инфраструктурасы һәм коммуналь инфраструктура объектларыннан, биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдаланучы шушы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата әлеге Законда һәм башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өстәмә таләпләр билгеләнгәндә аларга туры килгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан югары технологияләр өлкәсендәге технопаркка һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенә карата өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның идарәче компаниясенең бу таләпләргә туры килүен раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

3. Икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренең реестрын алып баруны гамәлгә ашыра. Әлеге реестрны алып бару тәртибе күрсәтелгән вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.»;

5) 19 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) конгресс һәм (яисә) күргәзмә чараларын, ярминкәләр (шул исәптән халыкара) үткәрүне оештыру яисә аларны үткәрүдә ярдәм итү аша;».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына төзәтмәләр таблицасы**

| № т/б | Татарстан Республикасы законының гамәлдәге редакциясе | Беренче укылышта кабул ителгән закон проектының статьялары тексты | Төзәтмә тексты, аның авторы | Төзәтмәләрне исәпкә алган закон проектының статьялары тексты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 6 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтләре**<br><br>1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:<br>…<br>6) федераль законнарда, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән кызыксындыру чараларын индустриаль (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль | 2) 6 статьяда:<br>а) 1 өлештә:<br>6 пунктта «идарәче компанияләренә» сүзләреннән соң «югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә,» сүзләрен өстәргә; | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты**<br><br>2 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br>«2) 6 статьяның 1 өлешендә:<br>а) 6 пунктта «идарәче компанияләренә» сүзләреннән соң «югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга, югары | 6 статья. **Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтләре**<br><br>1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:<br>…<br>6) федераль законнарда, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән кызыксындыру чараларын индустриаль |

| № т/б | Татарстан Республикасы законының гамәлдәге редакцисе | Беренче укылышта кабул ителгән закон проектының статьялары тексты | Төзәтмә тексты, аның авторы | Төзәтмәләрне исәпкә алган закон проектының статьялары тексты |
|---|---|---|---|---|
| | (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләренә, сәнәгать технопаркларына, сәнәгать технопаркларының <u>идарәче компанияләренә,</u> сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына бирү максатларында аларга карата өстәмә таләпләр билгели;<br>7) Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать <u>технопаркларына</u> һәм сәнәгать кластерларына Татарстан Республикасы мөлкәте һәм бюджеты акчалары исәбеннән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын бирү тәртибен раслый, шулай ук бюджет акчаларын максатчан куллануны тикшереп тора;<br>…<br><u>11) Татарстан Республикасы</u> | 7 пунктта «технопаркларына» сүзеннән соң «, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга» сүзләрен өстәргә;<br>11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;<br><u>б) 2 өлештә:</u><br><u>7 пунктта «технопаркларын» сүзеннән соң «, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларны» сүзләрен өстәргә;</u><br><u>9 пунктта «сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренең,»</u> | технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә,» сүзләрен өстәргә;<br>б) 7 пунктта «технопаркларына» сүзеннән соң «, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга» сүзләрен өстәргә;<br>в) 11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;» | (сәнәгать) паркларга һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләренә, сәнәгать технопаркларына, сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренә, <u>югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренә,</u> сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына бирү максатларында аларга карата өстәмә таләпләр билгели;<br>7) Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларга, сәнәгать технопаркларына<u>, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларга</u> һәм сәнәгать |

| № т/б | Татарстан Республикасы законының гамәлдәге редакцисе | Беренче укылышта кабул ителгән закон проектының статьялары тексты | Төзәтмә тексты, аның авторы | Төзәтмәләрне исәпкә алган закон проектының статьялары тексты |
|---|---|---|---|---|
| | Дәүләт Советына ел саен Татарстан Республикасында сәнәгать торышы һәм үсеше турында, Татарстан Республикасында сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын гамәлгә ашыру хакында доклад тапшыра; | сүзләреннән соң «югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның, югары технологияләр өлкәсендәге технопаркларның идарәче компанияләренең,» сүзләрен өстәргә; | | кластерларына Татарстан Республикасы мөлкәте һәм бюджеты акчалары исәбеннән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын бирү тәртибен раслый, шулай ук бюджет акчаларын максатчан куллануны тикшереп тора;<br>… |
| 2. | 12 статья. **Индустриаль (сәнәгать) парклар**<br>…<br>4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендәге вәкаләтле органы әлеге статьяда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган индустриаль (сәнәгать) паркларның, индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләренең реестрын алып бара һәм сәнәгать өлкәсендәге | | **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты**<br><br>2 статьяга түбәндәге эчтәлекле яңа 3 пункт өстәргә:<br>«3) 12 статьяның 4 өлешендә «вәкаләтле органы» сүзләреннән соң «(алга таба – | 12 статья. **Индустриаль (сәнәгать) парклар**<br>…<br>4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисад өлкәсендәге вәкаләтле органы (алга таба – икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган) әлеге статьяда билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган индустриаль (сәнәгать) паркларның, индустриаль (сәнәгать) |

| № т/б | Татарстан Республикасы законының гамәлдәге редакцисе | Беренче укылышта кабул ителгән закон проектының статьялары тексты | Төзәтмә тексты, аның авторы | Төзәтмәләрне исәпкә алган закон проектының статьялары тексты |
|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлек субъектларына әлеге реестрдан өземтәләр бирә. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели. | | икътисад өлкәсендәге вәкаләтле орган)» сүзләрен өстәргә;»;<br><br>2 статьяның 3 һәм 4 пунктларын тиешенчә 2 статьяның 4 һәм 5 пунктлары дип санарга. | паркларның идарәче компанияләренең реестрын алып бара һәм сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына әлеге реестрдан өземтәләр бирә. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели.<br>... |